СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

25.07.2018 | с. Русское Макулово | 56-225

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы проекты турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Советының 27.09.2017 ел, № 39-161 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы проекты буенча түбәндәге составта тәкъдимнәр кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эш төркеме төзергә:

- эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башлыгы А.И. Матвеева;

эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Р. Цветкова;

Эшче төркем әгъзалары:

- Родионова О.Н. - Макыл мәдәният йорты мөдире;
- Баканова А.Н. - 7 нче Рус-Макыл сайлау округы депутаты;
- Росихина В.М. - пенсионер.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге проекты буенча 2018 елның 15 августында 10.00 сәгатьтә Макыл авылы мәдәният йортында Рус Макыл авылы, Үзәк урам, 125 йорт адресы буенча халык алдында тыңлаулар уздырырга.

6. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,<br>Югары Ослан муниципаль районы<br>Макыл авыл җирлеге башлыгы А. И. Матвеева